

Лəмберə районы vзенен кешелəре белəн бай. Шулай, килəчəк бу- ын вəкиллəре дə vзлəрен яхшы яклар- дан кvрсəтə. - Бу безнен, гомере буена Лəмберə поликлиникасында тырышып доктор булып хезмəт иткəн əбиебез Евгения Афанасьевна белəн, горурлыгыбыз! - ди Альберт Алимбек улы Еналеев, Лəмберə районында яхшы эшлəре белəн таныш кеше, оныгы Артурнын фотосурəтлəрен кат-кат яратып карый. Суворов училищесынын яшь курсанты vз хəрби формасында бик тə кvркəм кvренə һəм ничектер олкəннəрчə житди, кичəге мəшəкатьсез балачагы капка артында калган кебек. Чыннан да, ул, дvртенче сыйныфтан сон, тормышта менə шундый гади булмаган юл сайлап, бик иртə vсеп китте. Бу хакта анын беренче сvзлəре дə сойли: - Мин əле бала булганда, - дип сойлəгəн Артур “Призыв” газетасы хə- бəрчесенə, əнием мина һава-десант гаскəрлəренен Ульяновск шəһəрендəге Суворов училищесы турында видеоролик кvрсəтте. Миндə бик зур тəэсир калдырды һəм анда укырга керергə телəк туды. Бəхеткə, минем хыялым 2018 елда тормышка ашты. Бу хакта бер дə vкенмим, гəрчə анда уку бик жинел булмаса да. Без мəктəп программасын һəм махсус предметларны узабыз, мəсəлəн, хəрби əзерлек нигезлəрен. Бəялəрне дə мəктəптə кебек куялар. Остəвенə, катгый дисциплина, конебез минутлар буенча язылган. Һəм ин житди талəплəр физик əзерлеккə куела. Шəһəргə бары остазым белəн генə чыгам. Тик мина жинелрəк, училищеда да вокал торкемендə шо- гыльлəнəм бит, шуна кvрə кvп вакытны шəһəрдə vткəрəм. Ə парашют белəн унынчы сыйныфта гына сикерəчəкбез! Əлегə иртə.

Шуна суворовчы уллары, яраткан оныклары очен горурлыклары əти-əнисенен дə, ирле-хатынлы Еналеевларнын да анлашыла. Əлбəттə, яшь курсантка жинел тvгел, хəрби муштра бар, əмма ул зарланмый, шулай булырга тиеш тə дип уйлый.

Калашников автоматы жилкəсеннəн жиргə кадəр диярлек тошкəн суворовчы малайлар - кечкенə, əмма бик житди солдат. Менə ул армиябезнен килəчəге, андыйлар бирешмəс, чигенмəс; Ватаннын ык сакчылары!

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**